Шулай итеп, әлеге төр буенча белдерүләрне тикшергәндә гражданлык-хокукый килешүләр төзүнең иң элек законга ярашлыгы фактын тикшерү зарур. Бу очракта хезмәт мөнәсәбәтләре Россия Федерациясе Хезмәт кодексында ачык күрсәтелгән. Моннан кала, Вәкил фикеренчә, эш башкару өчен белгечләр җыйганда эш бирүченең аларны нинди юл белән җыюы исәпкә алынырга тиеш (таләп ителгән белгеч белән гражданлык-хокукый килешү төзелгән вакытта хезмәт закончалыгына ярашлы рәвештә эш бирүченең эшкә алу турында белдерү урнаштыру факты булуы, мәшгульлек хезмәте органнарының эшсез гражданнарны эшкә урнаштыру өчен эшкә бирүчегә җибәрелгән белгеч белән гражданлык-хокукый килешүе төзү факты булуы). Җитештерү имгәнүләре дәрәҗәсе югары булган өлкәләргә эшкә алу турында мәгълүмат булган белдерүләрне тикшергәндә аеруча игътибар таләп ителә.

Татарстан Республикасының дәүләт Хезмәт инспекциясе мәгълүматларына караганда 2015 елда җитештерүдә үлемгә китергән 66 бәхетсезлек очрагы теркәлгән. (2014 елда – 68, 2013 елда – 103).

Кызганычка каршы, җитештерүдә үлем очраклары кимү тенденциясе бар, дип әйтеп булмый, шул ук вакытта республикада җитештерүдә имгәнүләргә юл куймау өчен системалы эш алып барылуын танырга кирәк. Аңа производствода бәхетсезлек очракларына юл куйган эш бирүчеләрне җәзага тарту чаралары да, җитештерү имгәнүләре профилактикасы, һөнәри авырулар профилактикасы буенча чаралар керә.

Системалы эш алып барылуга карамастан, әгәр хезмәткәрләр эш бирүченең хезмәтне саклау буенча чаралар алып бару белән кызыксынмаса, эш тиешенчә булмый. Эш урынына хокук коллектив килешүендә каралган хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары дәүләт норматив таләпләренә туры килүе аерылгысыз дип кабул ителергә тиеш.

Хезмәткәрләрне хәвеф-хәтәрсез эш белән тәэмин итүдә шактый зур рольне профсоюз оешмасы уйный. Төзелеш өлкәсендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура, торак-коммуналь хуҗалык

министрлыгының координацияләүче роле игътибарга лаек. Татарстан Республикасы башкарма комитеты (Россия төзүчеләре профсоюзы) һәм Татарстан Республикасы Төзүчеләр берлеге белән берлектә күрсәтелгән министрлык тармак профсоюз оешмаларына коллектив килешүләргә җитештерү имгәнүләрен киметүгә, авыр һәм зарарлы хезмәт шартлары булган эш урыннарын кыскартуга, хезмәт шартларын махсус бәяләүгә юнәлтелгән чаралар керттерергә һәм аларны тормышка ашыруга кирәкле булган акчаны бүлдерүгә иреште.

Коллектив килешүләрендә профсоюз органнары эшчәнлеге белән бәйле хезмәтне саклау турында киңәйтелгән бүлек булган оешмалар саны арту тенденциясе, Вәкил фикеренчә, алга таба да хезмәтне саклау дәүләт идарәсе системасын үстерү өчен яхшы ярдәм.

## Торак хокукларын саклау

Республикада торак төзелеше темплары кимеми, һәм Татарстан бу күрсәткеч буенча Россия Федерациясе субъектлары арасында лидерларның берсе булып кала. Татарстанстат мәгълүматларына караганда 2015 елда республикада 2405,5 мең квадрат метр торак сафка бастырылган. Күп квартирлы инвестицион торак программасы буенча 130 һәм кечкенә катлы төзелеш программасы буенча 10082 йорт төзелгән. 661 өлешче квартира алган 4 проблемалы өлешләп төзелгән йорт файдалануга тапшырылган.

Торак шартларын яхшырту программалары буенча 249 Бөек Ватан сугышы ветераны, 70 гаилә торак шартларын яхшырткан. Күп балалы гаиләләр тарафыннан 45 торак сертификаты үзләштерелгән. Тагын 42 гаилә федераль бюджеттан дәүләт торак сертификатлары белән тәэмин ителгән.

Федераль һәм республика торак программаларын тормышка ашыру, шулай ук ипотека торак кредиты базарын үстерүгә карамастан, халыкның кайбер катлавы өчен элеккечә дәүләт яки муниципаль торак фондыннан торак биналарын алып тору (найм) торак шартларын яхшыртуның бердәнбер

мөмкинлеге булып кала. Социаль найм килешүе буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исемлегендә дистәләгән мең кеше тора.

Муниципаль торак төзелмәгәнлектән, җирле үзидарә органнарының муниципаль торак фондының буш торган яки теге яки бу сәбәпләр аркасында бушаган (гражданнарны суд карары нигезендә чыгару, ялгыз гына яшәүченең үлеме һәм башкалар) квартирлар (бүлмәләр) исәбенә социаль найм килешүе буенча торак биналары бирү буенча нәтиҗәле эшен оештыру зарур. Практика күрсәткәнчә, муниципаль торак фондын бүлмәүнең төп сәбәпләре булып, аларның яшәргә яраксызлыгы, шул исәптән, күп катлы йортны аварияле дип танымау очраклары, коммуналь хезмәтләр буенча элек яшәүчеләрдән калган бурыч тора, гамәлдәге законнар нигезендә әлеге бурыч  социаль найм буенча килешү төзелгән затларга күчми.

Әйтик, Казанда яшәүченең аңа социаль найм килешүе буенча торак бирү турында суд карарын үтәмәүләре турында шикаятен тикшерү барышында шул ачыкланды, 2014 елда Казан шәһәре башкарма комитеты гражданнарны аварияле торак фондыннан күчерү буенча адреслы муниципаль  программаны үтәү максатларында,  аварияле дип табылган йортлардан гражданнарны күчерү планлаштырылган 85 буш квартирны ачыклаган һәм тикшергән. Ләкин, башкарма комитеты мәгълүматы буенча барлык 85 буш квартир да канәгатьләнмәслек хәлдә һәм аларга  ремонт кирәк.

Берничә дистә квартирның яшәргә яраксызлыгы бер көн эчендә генә килеп тумаган. Әлеге мисал уңаеннан, тулаем шушы хәл уңаеннан, Вәкил муниципаль торак төзелмәгәндә буш торучы яки яшәүчедән азат ителгән торак биналары исәбенә социаль найм килешүе буенча квартирлар бирү ресурсы  нәтиҗәле файдаланылырга тиешлеген билгеләп үтә.

Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм  калган балаларның, ятимнәрнең торакка хокукларын тормышка ашырганда акча җитәрлек булмаганда оптималь карарлар табарга кирәк. 2015 елда 331 кеше торак сайлап, Татарстан Республикасының махсус торак фондыннан бирелгән торакка найм килешүе

төзеделәр. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматлары буенча 2015 елның 31 декабренә мохтаҗ дип табылган, әмма махсус торак фондыннан торак белән тәэмин ителмәгән ятимнәр һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, 18 яшькә җиткән балалар саны 1265 булган.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматларына караганда, торак белән беренче чиратта, ятимнәр һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан алдан исәпкә куелганнары тәэмин ителә.

2013 елның 12 гыйнварында дөнья күргән 8-ЗРТ нче «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 өлеш 3 нче маддәсенә һәм «Татарстан Республикасында халыкны адреслы социаль яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 8 нче маддәсенә кертелгән үзгәрешләргә ярашлы рәвештә, торак ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, акылы зәгыйфь балаларга бирелә.

Күрсәтелгән норма буенча торак белән тәэмин итү өчен шәхесне исәпкә кую көне түгел, ә 18 яшькә җитү һәм торак белән тәэмин итү турында гариза бирү юридик әһәмиятле.

Шулай итеп, Вәкил фикеренчә, торак бирү буенча ресурслар кытлыгы шартларында, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тиешле гаризалары булган очракта, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан аларга закон буенча тиешле торакны алмау вакытыннан чыгып эш итәргә тиеш. Киресенчә булган очракта, торак белән вакытында тәэмин итмәгәндә, муниципаль берәмлекләр хакимиятләре вакытында мохтаҗлык фактын теркәмәгән ятим балалар хокуклары бозылачак.

Алга таба ятим баланың 18 яшькә җиткәнче мәгариф оешмаларында, медицина оешмаларында яки социаль хезмәтләр күрсәтә торган оешмаларда булу вакытында торак биналары даими яшәү өчен яраксызга яки торак биналары өчен билгеләнгән санитар һәм техник кагыйдәләргә һәм

нормаларга җавап бирми торган хәлләргә юл куймау буенча тиешле чаралар күрү мөһим.

Тагын шунысын да билгеләргә кирәк, торак белән тәэмин итү хокукына социаль найм килешүе буенча торак биналарында яшәп торучы яки яшәү мөмкин түгел дип табылган торак милекчеләре булган, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар ия. Гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә, торакта яшәүне тану өчен анда бу ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга карата ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгәннәр яшәп тору мөмкин түгел. Билгеле, балигъ булмаган бала мондый гариза белән судка мөрәҗәгать итми. Ятим балаларның әлеге категориясенә карата бәхәсле хәлләрдән котылу өчен опека органнары һәр очракта, вакытында торакны мәҗбүри алыштыру турында баланың законлы вәкилләренең гаризасын судка җибәрү турында кайгыртырга тиеш.

Милекчеләр яки торак алып торучы ятим балаларның торакка хокукларын тормышка ашыру, аерым алганда, торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү мәсьәләсе дә аерым игътибар сорый. 2015 елда Вәкил ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның торак-коммуналь хезмәтләр алдындагы финанс йөкләмәләрен үтәү өлкәсендәге законнарны камилләштерү мәсьәләләре буенча эшче төркем эшендә катнашты.

Әлеге мәсьәләне өйрәнү барышында ятим балаларга беркетелгән тораклардагы торак-коммуналь хезмәтләр өчен бурычлар җыелуның төп сәбәбе – бу ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән ата-аналар, шулай ук бу торакларда теркәлгән тәртипсез туганнары бурычлары. Шулай итеп, ятим баланың өенә кайткач торак-коммуналь хезмәтләрнең бурычлы кешесе булуы гадел түгел.

Ятим балаларның торак-коммуналь хезмәтләр алдындагы бурычларын киметү эше системалы булырга тиеш. 2015 елның 1 ноябренә ятим балаларның торак һәм коммуналь хезмәтләр түләүгә шактый бурычы җыелган, ул Казанда – 7,5 млн. сум, Яшел Үзәндә – 2 млн. сум, Саба

муниципаль районында – 381404 сум, Биектау муниципаль районында – 361 мең 986 сум. Коммуналь хезмәтләр өчен законсыз исәпләүләргә игътибар итү практик әһәмиятле эшнең бер өлеше. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2015 елда судларга мондый эшләр буенча 146 дәгъва кергән, 102 очракта балигъ булмаганнарга карата уңай карарлар чыгарылган.

Республикада Бөек Ватан сугышында катнашучыларны һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарын торак белән тәэмин итү буенча зур эш алып барыла. Моңа карамастан, кызганычка каршы, агымдагы елда без ветераннарның озак вакытлар яшәү өчен яраксыз дип табылган һәм төзекләндерергә мөмкин булмаган торакларда яшәвен һәм билгеләнгән закон тәртибендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылмавын ачыкладык.

Мәсәлән, массакүләм мәгълүмат чараларының берсендә басылган мәкалә буенча, яшәргә яраксыз дип табылган һәм сүтелергә тиешле күп катлы йортта яшәүче Бөек Ватан сугышында катнашучының торак шартларын яхшырту буенча Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының чаралар күрмәве турында мәгълүматны тикшердек. Тикшерү барышында бу хатын-кызны торакка исәпкә бастыру турында карар кабул итүләре ачыкланды.

Ахырда, тораклары (алар өчен бердәнбер булган) яшәү өчен яраксыз дип табылган һәм төзекләндерергә мөмкин булмаган һәм торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ сыйфатында исәптә тормаучы Бөек Ватан сугышында катнашучыларны торак шартларын яхшырту өчен исәпкә кую буенча чаралар күрү турында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләре адресына хатлар җибәрелде. Шуннан соң без ветераннар яшәгән йортларны яшәргә яраксыз һәм сүтелергә тиешле дип тану турында карар чыккан соң, башкарма комитетларның берничә көн дәвамында ветераннарны исәпкә куюлары турында мисаллар китерелгән мәгълүматлар алдык. Без Бөек Ватан сугышын узган кешеләргә

карата хөрмәт күрсәтергә тиешбез.

Торaклары төзүчеләр гаебе белән судта үзбелдеклеләнеп төзелгән дип танылган гражданнарның хокукларын тәэмин итү дә актуаль тема булып кала. «Свей» фирмасының 9 катлы йортка рөхсәт алып та, 18 катлы йорт төзү, ялган коттеджларны сүтү темасы массакүләм мәгълүмат чараларында киң яктырылды.

Торак бинасын (аның бер өлешен) үзбелдеклеләнеп төзү дип тану турында дәгъва гаризалары күбрәк Казан шәһәре судларына керә. Бу уңайдан без, үзбелдеклеләнеп төзегән биналарны үз вакытында ачыклау һәм алар буенча чаралар кабул итү буенча «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының шәһәр төзелешенә рөхсәт бирү идарәсе»н тикшердек. Аның барышында шул ачыкланды, үзбелдеклеләнеп төзү объектларын ачыклау һәм аларга чик кую чараларын кылу өчен «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының шәһәр төзелешенә рөхсәт бирү идарәсе» хезмәткәрләренә төрле вакыт аралыгы таләп ителгән. Кайбер объектлар буенча беренчел караудан башлап бинаны үзбелдекләре белән төзегән дип тану турында дәгъва бирү вакытына кадәр ярты елдан артык вакыт узган, шул ук вакытта кайберләре буенча сизелерлек аз вакыт таләп ителгән

Йортларны үзбелдекләнеп төзелгән дип тану һәм аларны сүтү турында суд карары кабул ителергә мөмкин булган торак йортларда квартир сатып алуны булдырмау буенча үз вакытында күрелмәгән чаралар, объектларны беренчел караудан башлап судка дәгъва бирү вакытына кадәр үзбелдеклеләнеп төзелгән йортларда торак алган гражданнарга сизелерлек матди зыян китерергә мөмкин. Моннан тыш, дәгъваны тәэмин итү сыйфатында килешүне тыю турында юллама белән торак йортны үзбелдеклеләнеп төзелгән дип тану турында дәгъва бирү вакытын сузу намуссыз төзүчеләргә сатып алучылар табылмаган биналарны сатарга мөмкинлек бирә. Шуңа күрә тикшерү нәтиҗәләре буенча дәгъва бирү турында, шул исәптән үзбелдеклеләнеп төзү объектларны беренчел карау

вакытыннан башлап дәгъва бирү буенча чаралар кабул итүне көйләгән карарлар чыгару юлы белән карарлар кабул итүгә дифференцияле карау очракларын бетерергә кирәк.

Контроль-күзәтчелек органнары тарафыннан яклау тапмыйча, кешеләр даими төстә Вәкилгә идарәче компанияләр өстеннән шикаятьләр белән мөрәҗәгать итәләр. Тикшерүләр нәтиҗәләре буенча идарәче компанияләр адресына коммуналь хезмәтләр күрсәтүне туктату яки чикләү, торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен бурычлар түләү тәртибен бозу, шәхси исәпләү приборларын кабул итүгә нигезсез каршы килү очраклары буенча Вәкилнең заключениеләре җибәрелде. Вәкил фикеренчә, идарәче компанияләр тарафыннан җибәрелә торган хокук бозуларның берсе – “бурычлылар белән көрәш» дип атала. Торак-коммуналь хезмәтләр өчен акча җыю кирәкле эш, асылда бер йортта бурычлылар белән яшәгән кешеләрнең мәнфәгатьләрен күздә тота. Аны закон кысаларында башкарырга кирәк, һәм ул коммуналь хезмәтләрдән кулланучыларга зыян китермәскә тиеш. Киресенчә булганда, торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү өлкәсе татарстанлылар өчен көнүзәк тема булып калырга мөмкин.

**Сәламәтлек саклауга һәм медицина ярдәменә хокукларны саклау**

2015 ел сәламәтлек саклау реформасы билгесе астында үтте: медицина ярдәме күрсәтү тәртибе нигезендә формалаша торган хәлләр яки авырулар төркемнәре буенча, медицина ярдәме стандартлары, медицина ярдәме күрсәтү мәсьәләләре буенча клиник тәкъдимнәр (дәвалау беркетмәләре), махсуслашкан мәгълүмат системасы куллану белән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүне оештыру тәртибе буенча медицина ярдәме күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийлары расланды.

Республикада биш ел дәвамында халыкның артуы күзәтелә, Идел буе федераль округы төбәкләре рейтингында Татарстан Республикасы әлеге күрсәткеч буенча алдынгы урынны алып тора, Россия Федерациясе

субъектлары арасында беренче егермелеккә керә. Монда сәламәтлек саклау органнарының өлеше зур, йөрәк-кан әйләнеше системасы авыруларыннан үлү күрсәткече 26 процентка, балалар үлеме 6,1 процентка кимегән.

2015 елда республикада Татарстан Республикасында 2014-2018 елларга кеше хокуклары буенча Стратегиядә билгеләнгән, Татарстан Республикасында медицина ярдәме сыйфатын күтәрүгә юнәлтелгән күп кенә чаралар тормышка ашырылган: табибларның җаваплылыгын иминиятләү килешүе төзелгән, 2015 елда халыкның медицина ярдәме сыйфатыннан канәгатьләнү күрсәткече сораштырылганнарның 74,2 процентын (2014 елда – 67,6 процент) тәшкил итә, йогышлы булмаган авырулардан үлүне, куркыныч факторларны киметү максатыннан йөрәк-кан авырулары белән көрәш елын үткәрү кысаларында сәнагать предприятиеләрендә («Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе АҖ ( POZIS компаниясе), “Просто молоко» предприятиесе), артериаль басымны контрольдә тоту буенча эш урыннары оештыру буенча пилот проекты тормышка ашырылды, республиканың 48 медицина учреждениеләрендә артериаль басымны үзүлчәү постлары оештырылды. Кан тамырлары торышын һәм аның биологик яшькә ярашуын тикшерүнең заманча ысулын кертү буенча пилот проекты тормышка ашырыла.

Саналган уңышлар белән беррәттән, башлангыч медицина ярдәме күрсәтү өлкәсендә, шулай ук дару белән тәэмин итү өлкәсендә проблемалы мәсьәләләр кала.

Вәкил адресына медицина ярдәме алуга һәм аның сыйфатына кагылышлы шикаятьләр даими килеп тора. Мәсәлән, Вәкил үткәргән “Кайнар элемтә»дә бер көн дәвамында медицина ярдәме күрсәтүнең сыйфаты буенча 104 граждан мөрәҗәгать итте. Гражданнарның шикаятьләрен караудан тыш, Вәкил “Сырхауханәләр һәм хастаханәләр» төрен үз эченә алган “Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасының баш модераторы вазифасын да башкара.

«Сырхауханәләр һәм хастаханәләр» төрендәге гаризаларны анализлау

сәламәтлек саклау өлкәсендә медицина ярдәме алу, халыкка хезмәт күрсәтү сыйфаты буенча берничә проблеманы ачыкларга мөмкинлек бирде.

Шуларның берсе, шул исәптән дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә дә күрсәтелүче түләүле медицина ярдәмен үстерү процесслары яссылыгы аша, дәүләт гарантияләре программасына ярашлы рәвештә гарантияле медицина ярдәме күләменә гражданнар хокукларын тормышка ашыруга бәйле. Россия икътисад үсеше министрлыгында эшләнгән 2015 елга һәм 2016, 2017 елларның планлы чорына социаль-икътисадый үсеш фаразлары буенча илнең халыкка түләүле хезмәт күрсәтү базары структурасында медицина хезмәтләре өлеше базар күләменең 6 процентын били.

Түләүсез нигездә йөрү өлешенең дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләре күрсәтә торган түләүле хезмәтләр өлешенә ярашлыгы проблеманың индикаторы дип кабул ителә. Безнең фикерчә, әлеге күрсәткеч информатив, ләкин, шәхси клиникаларга җибәрелмичә, асылда бушлай медицина хезмәте алучы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләренә мөрәҗәгать итүчеләрнең гомуми саны кимү, шул ук вакытта гражданнар арасында бушлай медицина хезмәте урынына түләүле медицина хезмәтләре алу таралу белән аңлатыла торган күп факторлар аркасында үзгәреп тора.

Булган кимчелекләр кеше факторы белән бәйле: пациентларның күп агымы белән беррәттән медицина оешмасында кадрлар кытлыгы, кирәкле медицина җиһазлары булмау, сәламәтлек саклау учреждениесе җитәкчелеге ягыннан җитәрлек контроль булмау, халыкның терапевт юлламасыннан башка гына түләүле хезмәтләр кабинеты аша тар белгечләр каравына эләгә алуын сайлавы.

Мәсәлән, Казанда яшәүче балигъ булмаган баласының медицина күзәтүе узу өчен Казан шәһәренең «7 нче шәһәр балалар клиник хастаханә»сенә неврологка һәм окулистка эләгә алмавы һәм учреждение педиатрының түләүле клиникага мөрәҗәгать итәргә кушуыннан зарланып мөрәҗәгать итте. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы

төр модераторы буларак кадрлар кытлыгы аркасында тар белгечләр кабул итү буенча кыенлыклар турында җавап урнаштыра.

Медицина өлкәсендә түләүле хезмәтләр секторы ачыклыгы пациенттан түләү алу гадәтен кертергә тиеш түгел, ә асылда дәүләт гарантияләре программасы кысаларында медицина ярдәме күрсәтүне урнаштырырга тиеш. Мәсәлән, «Халык контроле» системасында Яр Чаллы шәһәренең «5 нче шәһәр хастаханәсе»нең кабул итү бүлегенә ашыгыч күрсәткечләр буенча кергән пациентка түләүле нигездә УЗИ үткәрү факты теркәлгән ( соңрак алга таба мондый хәлләргә юл куймас өчен оештыру чаралары күрелде).

Вәкил фикеренчә, «Халык контроле» системасындагы «Сырхауханәләр һәм хастаханәләр» төре буенча кайбер белдерүләр гражданнарның бушлай медицина ярдәме алуга дәүләт гарантияләре программасына ярашлы рәвештә, планлы медицина ярдәме күрсәтү чикләрендә диагностика тикшеренүләре үткәрү, медицина ярдәме күрсәтү күләме һәм сроклары, шул исәптән көтү вакыты турында белмәвен күрсәтә.

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты 2015 елның декабрендә үткәргән медицина оешмалары сайтлары мониторингы гражданнарның хәбәрдарлыгы өлешендәге хокук бозуларның системалы булуын күрсәтә. Бу медицина оешмалары җитәкчеләренең әлеге эшне оештыруга игътибары җитәрлек булмавын дәлилли.

Кайбер сәламәтлек саклау оешмаларында мониторинг үткәрү чорында госпитализация кагыйдәләре һәм сроклары турында (Актаныш, Әтнә, Лениногорск, Нурлат үзәк район хастаханәләре), медицина хезмәткәрләре турында (Баулы, Буа үзәк район хастаханәләре), кулланучылар хезмәтләре турында фикерләр (Казан шәһәренең «7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» оешмасы, Бөгелмә үзәк район хастаханәсе), диагностик тикшеренүләргә әзерлек кагыйдәләре турында (Әтнә, Саба үзәк район хастаханәләре), бушлай медицина ярдәме турында (Азнакай үзәк район хастаханәсе), халыкны диспансеризацияләү вакытлары, тәртибе һәм нәтиҗәләре турында (Минзәлә, Яңа Чишмә үзәк район хастаханәләре ) мәгълүмат урнаштырылмаган.

Кайбер медицина оешмаларының (Алексеевский, Кама Тамагы, Лаеш, Мамадыш, Минзәлә, Мөслим үзәк район хастаханәләре һәм башкалар) персональ сайтлары юк. Сәламәтлек саклау порталында Менделеев үзәк район хастаханәсе турында урнаштырылган мәгълүматта персонал һәм дәүләт гарантияләре программасы турындагы хәбәр генә бар. Ә Сарман үзәк район хастаханәсе турында мәгълүмат бөтенләй юк.

Медицина оешмалары сайтларын, медицина оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатының бәйсез бәяләвен үткәрү өчен кирәкле мәгълүмат белән тутыру, аны яңарту уңаеннан камилләштерү – медицина оешмалары җитәкчеләренең даими игътибарында булырга тиеш.

Халыкның сәламәтлеге күрсәткечләренең тотрыклы уңай үсешенә ирешү өчен Татарстан Республикасында медицина ярдәменең сыйфаты, аның һәркемгә күрсәтелүе зур әһәмияткә ия. Шуның белән бергә компетентлы органнарның мәгълүматларын анализлау бу өлкәдә проблемалар булуын күрсәтә.

Әйтик, мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды мәгълүматлары буенча 2015 елда нигезле шикаятьләрнең төп сәбәпләре булып түбәндәгеләр тора: медицина оешмасы эшен оештыру, мәҗбүри медицина иминияте программалары буенча медицина ярдәме күрсәтүдән баш тарту, медицина хезмәте сыйфаты, мәҗбүри медицина иминияте программалары буенча акча алу. Күпчелек очракта медицина оешмалары үзләре дә иминиятчеләр нәтиҗәләре һәм гариза бирүчеләр дәлилләре белән килешә. Нигезле дип табылган шикаятьләрнең күпчелеге (91,6 процент) судка кадәр үк канәгатьләндерелә. Территориаль фондка һәм иминият медицина оешмаларына иң күп шикаять Казан шәһәренең «7 нче шәһәр клиник хастаханәсе», Чаллы шәһәренең «5 нче шәһәр хастаханәсе», Казан шәһәренең «20 нче шәһәр сырхауханәсе», Яр Чаллы шәһәренең « 3 нче шәһәр клиникасы», Түбән Кама, Бөгелмә, Кама Аланы, Лениногорск, Яшел Үзән үзәк район хастаханәләре өстеннән килгән.

Суд каравына кадәр барып җиткән бәхәсле очракларда дәгъваларның яртысы диярлек канәгатьләндерелгән. Канәгатьләндерү сәбәбенең иң киң таралганы – күрсәтелгән медицина ярдәме сыйфаты белән бәйле эшләр (77 процент).

Медицина ярдәме күрсәтү сыйфаты мәсьәләләре аны күрсәткәндә куркынычсызлыкны тәэмин итү белән дә бәйләнгән. Мәсәлән, кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстандагы идарәсе дәгъвасы буенча Сарман район суды Сарман үзәк район хастаханәсенең санитар законнарны бозуларны бетерү буенча тиешенчә эшләмәвен таныган. Суд карарын үтәүгә кадәр медицина оешмасының пациентларга рентгенодиагностик тикшеренүләр үткәрү эше физик факторлар чыганаклары белән эшләү шартлары турында (ионлашкан нурланыш – радиация) санитар-эпидемиологик заключениесез башкарылган.

Шулай итеп, нигезле шикаятьләр арту шартларында сыйфат менеджменты системасы кертү, медицина эшчәнлеге сыйфатының эчке контролен оештыру кирәклеге тагын да актуаль булып кала.

Гражданнарның авыруның иртә чорында ук медицина ярдәме алу мөмкинлеге гражданнарның сәламәтлек саклауга хокукын тормышка ашыруның мөһим аспекты булып тора.

Узган 2015 елда Татарстан Республикасының кайбер муниципаль районнарында туберкулез белән авыру очраклары арту күзәтелде. 2015 елның тугыз ае йомгаклары буенча бу күрсәткеч узган елның шул чоры белән чагыштырганда Әтнә, Югары Ослан, Зәй, Минзәлә, Сарман, Ютазы районнарында ике, аннан да күбрәк тапкыр арткан. Моннан тыш, Яңа Чишмә муниципаль районында 2015 елда да авыруның артуы дәвам иткән.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматлары буенча, авыру арту туберкулез белән авыруның югары куркынычтагы социаль төркеменә керүче затлар белән бәйле.

Шуның белән бергә Әтнә муниципаль районында беренче тапкыр

ачыкланган авырулар: учреждениеләр хезмәткәрләре, пенсионерлар. Авыру артуның төп сәбәпләреннән берсе – озак вакыт (өч-биш ел, аннан да күбрәк) флюорография узмау.

Кызганычка каршы, 2015 ел йомгаклары буенча халыкның онкологик авырулардан үлүе арту күзәтелә, 100 мең кешегә – 197,2 (2014 елда бу сан – 180,9).

Шуның белән бергә, Татарстанның кайбер муниципаль районнарында (Әлки, Зәй, Кайбыч, Кама Тамагы, Тәтеш) 2015 елның беренче яртыеллыгында 2014 елның шул чоры белән чагыштырганда беренче тапкыр яман шеш белән авыручыларның артуы теркәлгән.

Гражданнарның сәламәтлек саклауга хокукларын бозуга юл куймау өчен, Вәкил фикеренчә, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына өлкәннәрне, шул исәптән пенсионерларны, эшсезләрне үз вакытында профилактик медицина тикшеренүләренә җәлеп итү буенча, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә укучыларның флюорография тикшеренүләрен үткәрү, шулай ук онкологик авыруларны иртә ачыклау эшен оештыруга контрольне көчәйтү буенча чаралар күрү максатка ярашлы булыр иде.

## Уңайлы әйләнә-тирәлеккә кеше хокукларын саклау

Әйләнә-тирәлекне саклау проблемалары Татарстан Республикасы тормышында алдынгы урыннарның берсен алып тора. Экологик хәлгә җылылык энергетика комплексы һәм нефть сәнагате, химия, нефть химиясе һәм машина төзелеше, төзелеш комплексы һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләре тәэсир итәләр.

Сәнагать үсеше белән үрелгән социаль-икътисадый үсешкә омтылуга карамастан, экологиягә юнәлтелгән уңайлы әйләнә-тирәлек булдыру Татарстан үсешенең төп максаты булып кала, ул 2015 елның 17 июнендә дөнья күргән 40-ЗРТ номерлы закон белән расланган Татарстан

Республикасының 2030 елга кадәрге социаль-икътисадый үсеше Стратегиясендә чагылыш тапкан.

2015 ел башыннан ук экологик хәлне яхшырту буенча интенсив чаралар үткәрү елы булыр дип көтелде, шул уңайдан, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының 2014 елга докладында Татарстан Республикасы атмосферага күп зарарлы калдыклар чыгаручы (576,3 мең тонна), шул исәптән стационар чыганаклардан (293,7 мең тонна), күп ташландык сулар чыгаручы (439,4 миллион кубометр), бүлү челтәрләренә санитар-химик күрсәткечләрнең тиешле нормаларына туры килми торган су җибәрүче (11,9 процент), су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелмәгән системасында санитар-химик күрсәткечләр буенча нормаларга туры килми торган эчәр су бирүче (29,8 процент) Россия Федерациясе субъектлары рәтенә кертелде.

Шул ук вакытта атмосфера һавасы торышында сизелерлек үзгәрешләр күзәтелде. 2014 ел белән чагыштырганда шәһәрләрдә атмосфера пычрану дәрәҗәсе кимеде. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2014 елда һавага чыгарырга рөхсәт ителгән химик матдәләр күләме Казан шәһәрендә 28 мг/кубометр, Яр Чаллыда – 18, Түбән Камада – 17 мг/кубометр тәшкил итсә, 2015 ел нәтиҗәләре буенча ул 17, 11 и 8 тәшкил итте.

Әлеге нәтиҗәләр гомуми суммасы 1 247 500 мең сум булган бюджет акчасы исәбенә 291 максатчан табигатьне саклау чараларын тормышка ашыру аркасында ирешелде.

Моннан тыш, күрсәтелгән нәтиҗәләргә ирешү санкция чаралары куллану аркасында да мөмкин булды. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы мәгълүматлары буенча, республика судлары 71 предприятиенең эшен туктату турында карар кабул итте.

Бу мәсьәләдә гражданнар да активлык күрсәтте, алар «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына атмосфераны пычрату турында

шикаятьләр җибәрде. Аларда күкерт водороды, газ, төрле калдыклар исенә, аллергия, төтенгә зарландылар.

Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 4 декабрендә дөнья күргән указы белән агымдагы ел республикада Су саклау зоналары елы дип игълан ителде.

2015 ел йомгаклары буенча республика территориясенең су объектларына ташландык су ташлау белән көрәштә уңай үзгәрешләрне билгеләп үтәргә була.

Мисал өчен, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы мәгълүматлары буенча, хәзерге вакытта Октябрьский шәһәре биологик чистарту корылмаларын файдалану аркылы Ык елгасын алга таба да пычратмау, шулай ук 4700 м озынлыктагы канализация челтәрен алыштыру һәм алга таба биологик чистарту корылмаларын төзекләндерү тормышка ашырыла.

Моннан тыш, су объектларын экологик күзәтү кысаларында Татарстан Республикасы экология һәм табигый ресурслар министрлыгының махсуслашкан инспекциясе тарафыннан ай саен Ык тамагы һәм Кама елгаларыннан су үрнәге алына.

Шуның белән бергә, Ык елгасына ай ай дәвамында диярлек ташлык сулар агызу факты үзенә җәлеп итә, табигатьне саклау законнары таләпләрен саклау буенча тикшерү су объектына сизелерлек зыян китергәч кенә башкарылган.

Ташландык сулар ташлау темасы актуальлеге турында Татарстан Республикасы Хисап палатасы 2015 елда уздырган тикшерүләр дә раслый. Тикшерү нәтиҗәләре буенча алынган мәгълүматлар буенча 3564 үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү чыганакларының 10,5 проценты санитар нормаларга һәм кагыйдәләргә җавап бирми.

Анализ состояния канализация һәм чистарту корылмаларының торышын анализлау шуны күрсәткән, күп кенә торак пунктларында чистарту корылмалары канәгатьләнмәслек эшли, су объектларына халык сәламәтлеге

өчен куркыныч тудырган ташландык суларны ташлау дәвам итә. Татарстан Республикасы Хисап палатасы коллегиясендә яңгыраган мәгълүмат буенча, чистарту корылмаларының нәтиҗәсез эшләвендә искергән конструкцияләр, гидравликага басымның көчле булуы, корылмалардан канәгатьләнмәслек файдалану сәбәпче.

Элеккечә үк әйләнә-тирә мохитны саклау эшендә шәһәрләрне яшелләндерү әһәмиятле булып кала.

2015 елны Парклар һәм скверлар елы дип игълан итү яшелләндерү буенча күп кенә чаралар үткәрергә мөмкинлек бирде. Программаны тормышка ашыру кысаларында 140 яңа объект төзелде. Казанда гына да 700 яңа ылыслы һәм яфраклы агачлар, 6500 куак утыртылды, 35 км велосипед юллары булдырылды, 19,5 мең квадрат метр асфальт түшәлде, 1 меңнән артык яңа утыргыч, 1,5 меңнән артык яңа яктырткычлар урнаштырылды.

Шуның белән бергә, муниципаль берәмлекләр территорияләрендә законсыз чүплекләр барлыкка килү проблема булып кала. Күзәтчелек органнары мәгълүматлары буенча кайбер чүплекләр берничә мең квадрат метрга җитәргә мөмкин. Шундый чүплек Яшел Үзән районының Улитино авылы янында, Чувашстан белән чиктә ачыкланган.

2016 елның 5 гыйнварында Россия Федерациясе Президенты В.В.Путин «Россия Федерациясендә Экология елы үткәрү турында» указга кул куелды, аңа ярашлы рәвештә, 2017 елда Экология елы үткәреләчәк, аны үткәрү буенча оештыру комитеты оештырылган, хөкүмәт төп чаралар планын эшләячәк һәм раслаячак, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнарына Экология елы кысаларында үткәреләчәк тиешле чараларны тормышка ашырырга кирәк.

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Россия Федерациясендә Экология елы алдыннан аны әзерләү буенча чараларны үтәүдә актив катнашырга һәм экологик вәзгыятьне алга таба яхшыртуга ирешергә кирәк дип саный.

## Инвалидлар хокукларын яклау

Россия Федерациясенең 2006 елның 13 декабрендә инвалидлар хокуклары турында Конвенциягә кул куюы һәм ратификацияләве инвалидларның икътисадый, социаль, юридик һәм башка хокуклар буенча халыкара стандартларга юнәлтелгән шартларын формалаштыру турындагы мәсьәләләрне актуальләштерергә булышлык итте. Инвалидларны башка гражданнар белән бертигез транспортка, мәгълүмат һәм элемтәгә, шулай ук ачык яки халыкка тәкъдим ителә торган башка хезмәтләргә һәм объектларга хокукын тәэмин итү буенча тиешле чаралар кабул итүгә олы әһәмият бирелә. Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2015 елның 1 декабрендә расланган 1297 нче номерлы Россия Федерациясендә 2011-2020 елларга «Уңайлы тирәлек» дәүләт программасында күрсәтелгәнчә, инвалидлар һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнә торган катлавы өчен уңайлы тирәлек булдыру шәһәрләрдә, шулай ук авылларда яшәүче миллионлаган Россия Федерациясе гражданнары хокукларына һәм ихтыяҗларына кагыла торган социаль-икътисадый бурычларның берсе булып тора.

Татарстанда инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәтләнә торган катлавы өчен уңайлы тирәлек булдыру гражданнарны социаль яклау буенча дәүләт сәясәтенең аерылгысыз юнәлеше булып карала. Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматлары буенча 2014-2020 елларга “Татарстан Республикасында гражданнарны социаль яклау» дәүләт программасының «Уңайлы тирәлек» программасы кысаларында 2015 елда 101 социаль инфраструктура объекты (20 сәламәтлек саклау объекты, 22 социаль яклау һәм мәшгульлек объекты, 25 мәдәният объекты, 16 физик культура һәм спорт объекты, 18 профессиональ белем бирү учреждениесе) барлык төр инвалидлар өчен җайлаштырылган. Узган ел башында республиканың яхшы эше турында Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министры М.А.Топилин сөйләде, Казан һәм Сочины

Россиядә инвалидлар өчен иң уңайлы шәһәрләр дип атарга була дип белдерде.

Әйтелгәннәргә карамастан, инвалидларның уңайлы тирәлеккә хокукларын тормышка ашыру белән бәйле проблемаларын һәм дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары өчен хәзергә кадәр ачыкланмый калган башка проблемаларны аерып күрсәтергә була.

Инвалид өчен каршылыксыз тирәлек ул яши торган йорттан чыгу мөмкинлегеннән башлана. Бу уңайдан күпквартирлы йортларда яшәүче арбалы инвалидлар һәм йөрми торган инвалид балалары булган гаиләләргә, аларны инвалид яки инвалид бала ата-анасы милкендә булган квартирны югары каттан түбәнге катка алыштыру буенча ярдәм темасына тукталмый булмый. Россия Федерациясенең башка субъектларында моны уңай хәл итү тәҗрибәсе бар.

Федераль дәрәҗәдә бу мәсьәлә Россия Федерациясе хөкүмәтенең 1996 елның 27 июлендә дөнья күргән 901 нче карары белән расланган инвалидларга, инвалид баласы булган гаиләләргә аларны торак белән тәэмин итү, торак һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә ташламалар бирү кагыйдәләре белән көйләнә. Бу кагыйдәләргә ярашлы рәвештә Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары инвалидларның һәм инвалид баласы булган гаиләләрнең күчәргә ризалыгы булса һәм инвалидны тернәкләндерү индивидуаль программасына ярашлы рәвештә, түбәнге катка күчерүдә ярдәм итә ала. Асылда төбәкләрдә инвалидларга булышуның төрле юллары кулланыла.

Мәсәлән, Ханты-Манси автоном округы – Югра территориясендә автоном округы хөкүмәтенең 2012 елның 22 мартында дөнья күргән 110-п номерлы «Ханты-Манси автоном округы – Югра коммерциячел файдаланудагы торак фондыннан торак бүлеп бирү тәртибе турында» карары гамәлдә. Аңа ярашлы рәвештә, авыруы аркасында арбадан файдаланырга мәҗбүр булган инвалидларны түбән каттагы квартирларга күчерү максатыннан, үзенә хезмәт күрсәтү һәм хәрәкәт итү мөмкинлекләре

чикләнгән (өченче дәрәҗә) беренче төркем инвалидларга һәм үзенә хезмәт күрсәтү һәм хәрәкәт итү мөмкинлекләре чикләнгән (икенче дәрәҗә) икенче төркем инвалидларга квартирын Ханты-Манси автоном округы – Югра коммерциячел файдаланудагы торак фонды квартирына алыштыру мөмкинлеге каралган.

Массакүләм мәгълүмат чараларының интернет челтәрендәге мәкаләләрен анализлау шуны күрсәтте, бу проблема Кемерово өлкәсе җитәкчелеген дә борчый. Алар торак алыштыруга документлар җыйганда арбада йөрүче инвалидларга бушлай юридик ярдәм күрсәтергә карар иткәннәр.

2013 елдан башлап Татарстан республикасында Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды инвестицион программасына кертелә торган барлык торак йортлар проектлары беренче каттагы квартирларны аз хәрәкәтләнә торган гражданнар өчен йөрү юллары белән тәэмин итүне күздә тота.

Ләкин, кызганычка каршы, социаль ипотека программасы буенча кичектергесез булмаган һәм башка программаларда торак алу буенча яки социаль найм килешүе буенча исәптә тормаган инвалидларга карата системалы эш юк.

Мәсәлән, граждан мөрәҗәгать иткәннән соң, Лениногорск шәһәрендә яшәүче инвалид мәнфәгатен яклап, Вәкил җирле хакимияткә торак алыштыру вакытында инвалидка юридик ярдәм күрсәтергә тәкъдим итте. Җирле үзидарә вәкилләре күчемсез милек агентлыгына сорау җибәрде, әмма әлегә кадәр мәсьәлә хәл ителмәгән.

Асылда күпквартирлы йортларда ялгыз гына яшәүче, якыннары ягыннан даими ярдәм алу мөмкинлеге булмаган арбалы инвалидлар социаль инфраструктура объектларына бару түгел, квартирыннан чыгу мөмкинлегенә дә ия була алмый. Мондый хәлләргә юл куймас өчен республикага башка төбәкләр тәҗрибәсен куллану мәслихәт, мәсәлән, арбалы инвалидларның

торакларын социаль ипотека программасы буенча төзелгән торак исәбенә алыштыру практикасын куллану мөмкинлеген карарга кирәк.

Инвалидка башка гражданнар белән беррәттән социаль инфраструктура объектларына керү, шул исәптән шәхси транспорт чарасы яки җәмәгать транспортыннан уңайлы файдаланырга мөмкинлек бирүче чаралар белән тәэмин итү, тормышның мөһим өлкәсендәге хезмәтләргә һәм объектларга каршылыксыз керү шартларын формалаштыру нәтиҗәсе булып тора.

2015 елда без транспорт чараларын йөртүче яки җәмәгать транспорты пассажирлары булган инвалидлар өчен уңайлы тирәлек тәэмин итү белән бәйле кискен мәсьәләләр белән дә очраштык.

Казан шәһәрендә яшәүченең Казанның маршрут транспорт чараларының ишек төбенә бүлү уемнары куйганлыктан (болар пассажирларны исәпкә алу өчен куелган) арбалы инвалидларга һәм халыкның аз хәрәкәтләнә торган башка вәкилләренә йөрү чикләнү турында кергән шикаяте уңаеннан тиешле тикшерү үткәрдек. Тикшерү нәтиҗәсендә бүлү уемы төзек булмау очрагы ачыкланды, шунлыктан арбалы инвалидларның транспорттан файдалануы вакытында каршылыклар туган. Шикаятьне караганнан соң «Метроэлектротранс» предприятиесенә маршрут транспорт чараларының ишек төбенә куелган бүлү уемнарындагы тоткычлардан файдалану уңаеннан арбалы инвалидларның һәм халыкның аз хәрәкәтләнә торган башка вәкилләренең җәмәгать транспортында каршылыкка очрау очракларына юл куймау буенча өстәмә чаралар кабул итәргә, шулай ук аерым чыгу урыны турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим ителде.

Казан шәһәренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында муниципаль парковкадан (машина кую урыннары) файдаланган өчен түләү билгеләү турында (беренче һәм икенче төркем инвалидлардан тыш) шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендә дөнья күргән 181 нче законының 15 маддә 9 өлеше положениесен,

Таможня берлегенең «Тәгәрмәчле транспорт чаралары куркынычсызлыгы турында» (ТР ТС 018/2011) техник регламентына 3 нче кушымтаның 15.1 пунктын һәм Россия хөкүмәтенең 2000 елның 21 декабрендә дөнья күргән 998 нче карарын исәпкә алып, Казан шәһәре башкарма комитеты адресына өченче төркем инвалидларының муниципаль парковкаларда түләү очракларына юл куймау буенча чаралар күрүне тәкъдим иткән заключение җибәрелде. Ул Россия Федерациясе субъектларының социаль органнары яки Россия Федерациясе социаль иминият фонды аша алынган һәм инвалидларны тернәкләндерү яки инвалидлык профилактикасы өчен кабаттан җиһазландырылган җиңел автомобильләре булган өченче төркем инвалидларыннан, шулай ук гамәлдәге закон буенча бирелгән тәртиптә транспорт чарасын үзгәртүгә рөхсәте булган, инвалидлар куллану өчен махсус җиһазландырылган автомобильләрдә туктап торган өченче төркем инвалидларыннан акча алмауга кагыла. Заключениене карап, башкарма комитет тәкъдимнәрне үтәде.

Шуның белән бергә, 1968 елның 8 ноябрендә Венада кул кую өчен ачык булган юл хәрәкәте турында Конвенциягә өстәмә Европа килешүенә кушымтаның 18 пунктында (моңа Россия Федерациясе дә кул куйды) эчке законнар белән хәрәкәте чикле булган инвалидларга аларның транспорт чараларын дәүләт автоюлларында туктап тору урыннары тыелган җирләрдә куярга яки вакыты чикләнгән туктап тору урыннарында күрсәтелгән вакыттан күбрәк тоту рөхсәт ителә ала диелә.

Инвалидларның уңайлы тирәлеккә хокукларын тормышка ашыру белән бәйле югарыда күрсәтелгән документ положениеләрен тормышка ашыру кысаларында, Казан шәһәре башкарма комитеты хәрәкәте чикле булган өченче төркем инвалидлардан аларның автомобиле инвалидлык профилактикасы яки инвалидларны тернәкләндерү өчен җиһазлану-җиһазланмавына карамастан, туктау урыннары өчен акча алмаса да ярар иде.

Инвалидлар хокуклары турында Конвенциягә һәм илебез законнарына ярашлы рәвештә инвалидлар хезмәткә һәм эшсезлектән яклау хокукына ия.

Инвалидларны эшкә урнаштыруның үз үзенчәлекләре булуын исәпкә алу мөһим. Ул махсус эш шартлары булдыру, эш урыннарын тернәкләндерү шартларына ярашлы рәвештә кабат җиһазландыруны күздә тота.

Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматлары буенча мәшгульлек хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән инвалидларның яртысы гына (52 процент) эшкә урнаша ала. Вәкил фикеренчә, инвалидны эшкә урнаштыруга тәэсир итүче факторларның берсе – инвалид хезмәт эшчәнлеген тормышка ашырырга сәләтле очракларда индивидуаль тернәкләндерү программасында күрсәтелгән чаралар турында мәгълүматларның тулы булуы.

2015 елда иң күп инвалидлар эшкә урнашкан оешмалардан алынган мәгълүматларга караганда, хезмәткәр-инвалидларның индивидуаль тернәкләндерү программасы таләпләрен исәпкә алып тернәкләндерү чаралары үткәрү һәм махсус эш шартлары булдыру аерым кыенлыклар тудыра. Эш бирүчеләргә индивидуаль тернәкләндерү программаларында булган гомуми типтагы «махсус булдырылган шартларда эшли ала» яки «Бөтенроссия сукырлар оешмасы системасында эшли ала» дигән тәкъдимнәрне мөстәкыйль хәл итәргә кала. Нәтиҗәдә, эш бирүчеләр күрсәтүенчә, аларга тернәкләндерү программаларын тормышка ашыру ысулларына төгәллек кертү өчен берничә тапкыр медико-социаль экспертиза органнарына мөрәҗәгать итәргә туры килә.

Инвалидны эшкә алган эш бирүче позициясе аңлашыла. Аңа инвалидны эшкә урнаштырган өчен алган акчаны нәрсәгә тотарга кирәклеге ачык булырга тиеш. Инвалид хокукларын тәэмин итү күзлегеннән караганда, тернәкләндерү программасында булган мәгълүматларның тулылыгы аның һөнәри яраклашуына булышлык итә һәм эш шартлары тиешенчә булмаганда сәламәтлеге начараю куркынычын киметә. Медико-социаль экспертиза органнарының инвалидларның индивидуаль тернәкләндерү яки абилитация программаларында эшләү мөмкинлеге булган инвалидларның үрнәк мисалларын, шулай ук эш һәм ял режимын, эшнең авырлыгын,

киеренкелеген, эш урыннардагы санитар-гигиена шартларын, эш урыннарын җайлаштырганда техник чаралар тасвирламасын күрсәтүе бу мәсьәләне хәл итүнең уңайлы варианты булып тора.

Вәкил кабаттан психоневрология интернатларына урнаштырылган акылга зәгыйфь гражданнар хокукларын саклау темасына мөрәҗәгать итә. Узган ел Вәкил адресына Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының, министрлык карамагында булган психоневрология интернатларына гамәлдәге законнарда социаль хезмәт күрсәтү стационар учреждениеләреннән акылга зәгыйфь гражданнарны вакытлыча өйгә җибәрүне караган нормаларның булмавы турында мәгълүмат хаты җибәрүе турында хәбәр алынды. Бу хат уңаеннан психоневрология интернатлары туганнарга «ялга җибәрү» практикасын туктаткан.

Әлеге “ялга җибәрү» практикасын тыю акылга зәгыйфь дип табылган гражданның туганнары аның опекуннары булмаган очракта гына законлы һәм гражданнар хокукларын бозмый. Әлеге караш гамәлдәге гражданнар законнарының положениеләре белән нигезләнә. Россия Федерациясе Гражданнар кодексының 39 маддәсенә ярашлы рәвештә, элек билгеләнгән опекун яки попечительне аның вазифаларын башкарудан азат итү турындагы карар опека һәм попечительлек органнары тарафыннан, алар карамагындагы кешенең мәнфәгатьләренә каршы килмәгән очракта гына кабул ителә. Шулай итеп, акылга зәгыйфь гражданны психоневрология интернатына урнаштырганда опека һәм попечительлек органына элек билгеләнгән опекунның үз вазифаларыннан азат ителүе яки аның карамагындагы кеше мәнфәгатьләреннән чыгып опекун булып калуы турындагы хәлне ачыкларга кирәк.

Тормышта әлеге мәсьәләне бик тиз хәл итәләр. Психоневрология интернатлары урнашкан районнарның опека һәм попечительлек органнары биргән мәгълүматларга караганда, социаль хезмәт күрсәтүнең бу төр учреждениеләренә акылга зәгыйфь гражданнарны опекуннарының

вазифаларын башкарудан азат итмичә урнаштыру очраклары юк. Кагыйдә буларак, опекунның шәхси гаризасы нигезендә акылга зәгыйфь гражданны психоневрология интернатына билгеләүгә рөхсәт турында һәм акылга зәгыйфь кешене психоневрология интернатына урнаштыру вакытыннан алып гражданны опекун вазифаларыннан азат итү турында карарлар әзерләнә. Бары Түбән Кама муниципаль районыннан гына безгә гаризалар һәм документлар кабул иткән вакытта опека бүлеге белгеченең гражданнарга аларның опекун булып калу хокукын аңлатуы турында мәгълүмат керде.

Бу гамәлләр акылга зәгыйфь гражданнар мәнфәгатьләре икенче урында икәнне күрсәтә. Кызганыч, кайбер кешеләр өчен йортларында үз якыннары белән очрашулар болай да катлаулы тормышларында уңай тәэсирләр калдыра алыр иде.

Моннан тыш, элек аның опекуны вазифаларын башкарган граждан яшәгән торак пунктта акылга зәгыйфь кешенең милке булган очракта, аларга ике яки күбрәк опекун билгеләү максатка ярашлы булыр иде. Акылга зәгыйфь кеше өчен якын булган һәм элегрәк аның опекуны вазифаларын намус белән башкарган граждан үз карамагындагы кешенең милкен саклау буенча командировкага җибәрелгән учреждение хезмәткәренә караганда оператив һәм даими чаралар күрү буенча зуррак мөмкинлекләргә ия.

Шулай итеп, Вәкил фикеренчә, опека һәм попечительлек органнары акылга зәгыйфь гражданнарны медицина оешмаларына яки социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмаларга урнаштырганда, һәр очракта опекун белән аңлату эшләре алып барырга тиеш, аны вазифаларыннан азат итү аның карамагындагы кешенең мәнфәгатьләренә каршы килмәскә тиеш.

Инвалидлар өчен Татарстанда, тулаем Россия Федерациясе өчен характерлы булган проблемалар (тернәкләндерү техник чаралары белән үзвакытында тәэмин итмәү, пандуслар булмау һәм башкалар) актуаль булып кала. 2016 елның 1 гыйнварыннан федераль дәрәҗәдә инвалидлар хокуклары турындагы Конвенция буенча Россия Федерациясе йөкләмәләрен үтәү өчен күрелә торган чаралар хакында докладлар әзерләү турында

нормалар көченә керде, докладлар якын елларда халыкара килешүләрне үтәүгә күзәтчелек итү буенча вәкаләтле орган булган инвалидлар хокуклары буенча комитетка җибәреләчәк. Вәкил масштаблы чаралар (законнардагы үзгәрешләр, дәүләт проблемаларын чишү) инвалидларның социаль интеграциясенә юнәлтелгән конкрет чаралар белән алып барылыр дигән ышаныч белдерә.

### Миграция мөнәсәбәтләрендә кеше хокукларын саклау

2015 елда миграция мөнәсәбәтләре һәм үз иле территориясен хәрби низаглар аркасында ташлап китәргә мәҗбүр булган затлар адаптациясе темасы – Украинаның 2 миллионнан артык гражданын кабул иткән Россия өчен генә түгел, Якын көнчыгыш илләреннән килгән качакларны яшәтү һәм социаль яклауны тәэмин итү кирәклеге белән очрашкан барлык дөнья өчен дә актуаль булды. Миграция сәясәте буенча фикерләре төрле булуга карамастан, дәүләтләргә халыкара нормалар белән качаклар проблемаларын нәтиҗәле хәл итү һәм аларны саклау механизмнарын булдыру буенча вазифалар йөкләнгән. Чит ил гражданнарының хокукларын бозуга юл куймау максатыннан ихтыярсыздан күчәргә мәҗбүр булган Украина гражданнарын кабул итү, урнаштыру һәм документлар бирү буенча республикадагы хәл Вәкил тарафыннан даими күзәтелә.

Татарстан Республикасына барлыгы тугыз меңгә якын кеше килде, шуларның ике меңгә якыны – балигъ булмаганнар. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1390 нчы карарына ярашлы рәвештә, Вәкил Татарстан Республикасына сыену урыны эзләп килгән, Украина территориясендә даими яшәгән, гражданлыгы булмаган Украина гражданнарына хокукый ярдәм күрсәтү буенча Консультацион төркемгә керде. Мониторинг кысаларында, шулай ук Консультацион төркем эшчәнлеге кысаларында Вәкил һәм аның җаваплы кешеләре чит ил

гражданнарын вакытлыча урнаштыру пунктларына барды, аларның яшәү шартларын, медицина белән тәэмин ителешен тикшерде.

Татарстанда булу чорында, күчеп килергә мәҗбүр булганнарга медицина белән тәэмин итү буенча (3407 мөрәҗәгать буенча ашыгыч медицина ярдәме, 3291 мөрәҗәгать буенча планлы медицина ярдәме күрсәтелгән), эшкә урнаштыру буенча ( 3745 граждан эшкә урнаштырылган), социаль тәэминат буенча ( Украинаның 2595 гражданы матди ярдәм алган) һәръяклы ярдәм күрсәтелгән. 2015 ел ахырына Татарстан Республикасында хәрби хәрәкәтләр зонасында калган территорияләрдә яшәгән Украина гражданнары өчен 11 вакытлыча урнаштыру пунктлары эшләвен дәвам итте.

Килгән чит ил гражданнарының үз вакытында үз хокукый статусларын билгеләп, патентлар, вакытлыча яшәп тору өчен рөхсәт яки Россия Федерациясендә законлы булуга рөхсәт бирүче башка статус алулары мөһим. Чаралар күрмәү кешеләрнең законсыз булуын күрсәтә.

Вәкил адресына булган квота чикләрендә вакытлыча яшәп торырга рөхсәт ала алмаган гражданнардан гаризалар даими рәвештә килеп тора. Квотадан тигез файдалануны тәэмин итү максатыннан Россия Федераль миграция хезмәтенең Татарстандагы идарәсе 2014 елда аны бүлү буенча комиссия төзеде, шулай ук вакытлыча яшәп торуга рөхсәт алуга дәгъва итүче затларга туры килү шартлары һәм критерийләре кертелде. Шулай итеп, гражданнар яшенә, белеменә, белгечлеге буенча эш тәҗрибәсенә һәм хәтта республикада үзенең торагы булуга карамастан, комиссиядән өстенлекләр алырга мөмкин.

2015 елда әлеге практика принципиаль чишелеш алды. Татарстан Республикасы Югары судының административ эшләр буенча суд коллегиясенең апелляция шикаятен карау нәтиҗәләре буенча Россия Федераль миграция хезмәтенең Татарстандагы идарәсе каршында эшләүче вакытлыча яшәп торуга рөхсәткә квота бүлү буенча комиссия карарын законсыз һәм квота булганда законда каралмаган өстәмә таләпләр

билгеләнүе уңаеннан гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу дип тапты. Мондый карар Алтай краенда да бар.

2015 елдагы кебек, 2016 елда да вакытлыча яшәп торуга рөхсәт бирүне сорап мөрәҗәгать итүче чит ил гражданнарының саны билгеләнгән квотага караганда күбрәк булачагын искә алып, Россия Федераль миграция хезмәтенең Татарстандагы идарәсенә Россия Федерациясендә вакытлыча яшәп торуга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәткәндә квотаны чит ил гражданнарының үз хокукларын яклау өчен судка мөрәҗәгать итүен көтмичә, булган суд практикасын исәпкә алып каравын максатка ярашлы булыр дип уйлыйбыз.

2015 ел йомгаклары буенча Россия Федераль миграция хезмәтенең Татарстандагы идарәсенең чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча тоту махсус учреждениесендә тотылучы затларны Россия Федерациясе чикләреннән административ чыгарып җибәрү турында суд карарларын башкару сроклары кимүен әйтергә кирәк. Махсус учреждениедә тотылган чит ил гражданнарының 63 проценты бер айдан артмаган вакыт эчендә чыгарып җибәрелде.

Россия Федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе махсус учреждениесендә Таҗикстан Республикасы гражданнары озаграк тотыла, алар Россия Федераль миграция хезмәтенең Татарстандагы идарәсе җибәргән сорау хатына җавапны 4 ай, аннан да күбрәк көтәргә мәҗбүр.

Мисал өчен, Россия Федераль миграция хезмәтенең Татарстандагы идарәсе махсус учреждениесендә тотылучы, махсус учреждениегә 2015 елның 26 мартыннан урнаштырудан алып шушы көнгә кадәр яшәүче затка карата, ил консуллыгына Таҗикстан Республикасы гражданлыгы булу-булмавы турында сорау җибәрелгән 4 хат бүгенге көнгә кадәр җавапсыз кала. Тагын бер кешегә карата 2015 елның июленнән 2016 елның гыйнварына кадәр җибәрелгән шундый ук 4 сорау хаты да үтәлмәгән. Рәсми җаваптан башка затлар илдән чыгарыла яки гражданлыгы булмаган затлар дип танылa алмый, шунлыктан алар Россиядә калдырылды.

Мондый хәлләрдә Таҗикстан Республикасы гражданнарын административ чыгарып җибәрү турында суд карарларын тизрәк башкаруга булышлык итү максатыннан, Вәкил үзара хезмәттәшлек кысаларында, шулай ук Омбудсманнарның Азия берләшмәсе директорлары Советы әгъзасы статусын исәпкә алып, Таҗикстан Республикасының Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиленә килеп туган хәлгә игътибар итүне һәм кирәкле чаралар күрүне сорап хат җибәрде.

Гражданлыгы булмаган затларны илдән чыгарып җибәрүе тагын да кыенрак.

2015 елның декабрь ахырына Россия Федераль миграция хезмәтенең Татарстандагы идарәсе махсус учреждениесендә 133 кеше тотылды, шуларның 10ысы гражданлыгы булмаган затлар, аларның өчесе махсус учреждениегә 2014 елда ук урнаштырылган. Бу кешеләрне Россия Федерациясе чикләреннән чыгарып җибәрү яки аларның үзләре чыгып китүе чикне чыгу өчен гамәлдә булган документлары булмау аркасында мөмкин түгел.

Мондый хәлләрне исәпкә алып, гражданлыгы булмаган затларның хокукларын саклау өчен миграция хезмәте органнары белән суд приставлары хезмәте арасында хезмәттәшлекне көчәйтергә кирәк дип саныйбыз. Күздә тотылган ил гражданлыгы расланмау сәбәпле административ чыгарып җибәрү турында суд карарын башкару мөмкин булмау факты билгеләнгәндә Суд приставлары Федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе җитәкчеләренә кыска срокларда административ эш буенча эшне туктату турында судка мөрәҗәгать җибәрү һәм гражданлыгы булмаган затка Россия Федерациясендә законлы калу мөмкинлеге бирү максатка ярашлы булыр иде дип исәплибез. Мондый вакытта Россия Федераль миграция хезмәтенең Татарстандагы идарәсе хезмәткәрләренә гариза бирүчене икенче тапкыр тоткарламасыннар өчен затның законлы яшәве өчен кирәкле документларны эшләү буенча җаваплылык йөкләнә.

Гражданлыгы булмаган затларга күрсәтелгән чараларны кабул итү кирәклеге суд практикасы, шул исәптән, кеше хокуклары буенча Европа суды карарлары белән расланган ( мәсәлән, 2014 елның 17 июлендәге «Ким Россиягә каршы» дигән 44260/13 нче эше буенча).

Россия Федераль миграция хезмәтенең Татарстандагы идарәсенең чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны тотучы махсус учреждениесендә чит ил гражданнарын тоту шартлары һәм сроклары Вәкилнең даими контролендә кала.

## Пенитенциар система учреждениеләрендә тотылучы затлар хокукларын саклау

Вәкил пенитенциар системасы учреждениеләре эшенә контрольлек итү, шулай ук сак астына алынган һәм иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза узучы хөкем ителгән затларны тоту шартларына мониторинг үткәрү буенча даими эш алып бара. Тулаем алганда, Татарстан Репсубликасындагы пенитенциар учреждениеләренең канәгатьләнерлек эшен билгеләргә була. Ел дәвамында төзәтү учреждениеләрендә илнең төрле төбәкләрендә булган тәртипсезлекләргә, массакүләм каршылык акцияләренә юл куелмады. Тиешле тоту шартлары булдыру, шул исәптән, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы һәм Россия Федерациясе Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте объектларында инвалидлар өчен уңайлылык күрсәткечләрен арттыру буенча эш дәвам иттерелде.

Шул ук вакытта уңайлы социаль-психологик климат формалаштыру төзәтү учреждениеләрендәге тәрбия һәм төзәтү эшләре белән үрелеп алып барылырга тиеш. Бу җәһәттән җәзаларны үтәүгә хөкем ителүчеләр арасында наркотик матдәләр әйләнеше өлкәсендә (тотылган хөкем ителүчеләрнең гомуми санынннан 23 процenttан артык), шулай ук исерек хәлдә җинаять кылганнарның күп булуы игътибарны җәлеп итә.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе мәгълүматларына караганда, 538 наркотик кулланучы, 105 алкоголь бәйлелек белән җәфаланучы исәптә тора. Әлеге төркемнәрдә торучы кешеләр арасында кылынган җинаятьләр авырлыгы аеруча зур. Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе мәгълүматларына караганда, 2015 ел йомгаклары буенча 48 проценты, ягъни наркотик һәм психотроп матдәләр саклау, сату, әзерләү һәм эшкәртү өчен хөкем ителгән һәр икенче тоткын рецидивист булып тора.

Бу хөкем ителгәннәрне төзәтү һәм аларның яңа җинаятьләр кылуын кисәтү рәвешендә җәза үтәтү максатлары, төзәтү учреждениеләре хезмәткәрләренең психокоррекцион һәм тәрбия эшенә тулысынча ирешмәвен дәлилли. Рецидив җинаятьчелекнең югары дәрәҗәсе шулай ук күрсәтелгән гражданнарны тормышка яраклаштыру проблемалары белән дә бәйле. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән һәркем диярлек хезмәт, көнкүреш, медицина, психологик һәм хокукый характердагы проблемаларны хәл итүдә җирле үзидарә органнары катнашыннан башка мөмкин булмаган квалификацияле ярдәмгә мохтаҗ.

Иркутск өлкәсе пенитенциар учреждениеләренең наркобәйлелектән тернәкләндерү үзәкләре волонтерлары белән республика төзәтү учреждениеләренең хезмәттәшлеге буенча тәҗрибәсе кызыклы. Мондый оешмалар наркотикка бәйле булган кешеләр белән эшләүнең уникаль тәҗрибәсенә ия һәм тернәкләндерүнең нәтиҗәле программасын эшләү өчен мәйданчык буларак, хөкем ителүчене азат ителгәннән соң югалтмыйча, аны тернәкләндерүне наркобәйлелектән тернәкләндерү граждан үзәкләрендә дәвам итү өчен төзәтү учреждениеләрендә даими агарту эше алып бара алалар. Калининград өлкәсендә Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте идарәсе һәм наркомания белән бәйле авыру затларны тернәкләндерү үзәге арасында хезмәттәшлек турында килешү төзелгән.

Алкоголь бәйлелеккә дучар затлар белән эшләүдә шулай ук Россия төбәкләрендәге уңышлы тәҗрибәгә таянырга кирәк, мисал өчен, Красноярск

краена, анда 2006 елның ноябреннән Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте идарәсе учреждениеләрендә хөкем ителгәннәрне алкоголь бәйлелектән ирекле дәвалау проекты тормышка ашырыла. Бу вакыт эчендә 10 меңнән артык хөкем ителүче дәваланган. Татарстан Республикасында ирекле дәвалану буенча акция 2012 елда өч төзәтү учреждениеләрендә генә үткәрелгән һәм 25 хөкем ителүче генә җәлеп ителгән, 2015 елда бер төзәтү учреждениесендә 9 тоткын алкоголизмнан ирекле дәвалану узган.

Рецидив җинаятьчелекне кылуны булдырмау максатында, башка төбәкләрнең уңай тәҗрибәсен исәпкә алып, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсенә 2016 елда Татарстан төзәтү учреждениеләрендә тотылучы хөкем ителүчеләрне алкогольгә бәйлелектән ирекле дәвалау буенча проектны кабаттан, масштаблы итеп тормышка ашыру максатка ярашлы булыр иде.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе мәгълүматларына караганда, 2015 елның 12 аенда билгеләнгән тәртиптәге җәза үтәүнең хокук бозулар дәрәҗәсе 1000 затка исәпләгәндә 1427 очракны тәшкил итте. 2014 елда 1000 хөкем ителүчегә 1187 тәртип бозулар тәшкил итте. Колонияләрдә хокук бозулар саны арту һәм җинаятьләр рецидивының югары дәрәҗәсе хөкем ителүчеләрне вакытыннан алда шартлы рәвештә азат итү буенча булган практикага тискәре тәэсир итәләр.

Шул ук вакытта вакытыннан алда шартлы рәвештә азат ителү Вәкил һәм Татарстандагы Иҗтимагый күзәтү комиссиясе әгъзалары кабул итүләрендә һәм язмача мөрәҗәгатьләрендә хөкем ителүчеләрне иң кызыксындырган сорауларның берсе булып тора.

Төзәтү учреждениеләрендә хөкем ителүчеләрнең тәртибен бәяләү комиссияләре әгъзасы буларак, Вәкил 2015 елда «социаль лифтлар» буенча комиссияләр каравына вакытыннан алда шартлы рәвештә азат итү турында бирелгән 2916 юлламаның 2066 сы «социаль лифтлар» буенча комиссияләр тарафыннан уңай характеристика бирелгән кешеләр буларак яклануын билгеләп үтә (мөрәҗәгать иткән хөкем ителүчеләрнең 70 проценты). Шул ук

вакытта судлар 771 юлламаны гына канәгатьләндерде. (Гомуми санның 24 проценты).

Кабул ителгән суд карарларының законлылыгы һәм нигезлелеген тикшермичә, хөкем ителгәннәргә «социаль лифтлар» буенча комиссияләр тәкъдим иткән уңай характеристикалар белән вакытыннан алда азат итү турында юлламаны канәгатьләндерү буенча суд карарлары арасындагы сизелерлек аерманың сәбәпләренең берсе – беренчеләренең җитәрлек дәлилләмәве, ә хөкем ителүче аны азат итү өчен төзәлгән дип исәпләү өчен тиешле конкрет хәлләрне тулысынча күрсәтмәү тора.

Әлеге нәтиҗә Татарстан Республикасы төзәтү учреждениеләрендә законнарны күзәтүгә күзәтчелек буенча Түбән Кама прокурорының Менделеевский районы суды карарларын анализлау нәтиҗәләре белән дә раслана. Аның йомгаклары буенча шул билгеләнгән: төзәтү учреждениесе хакимиятенең судка җибәргән материалларында һәрвакытта да хөкем ителгәннәргә объектив-нигезле характеристикалар бирелми, бу суд эше буенча законлы һәм нигезле карар кабул итүгә тоткарлык итә.

Күрсәтелгән хәлләр законлылык, гаделлек һәм гуманлык принципларын саклауга турыдан туры йогынты ясый, хөкем ителгәннәрнең язмышында тискәре чагылыш таба, шулай ук аларны тормышка яраклаштыру эшенә комачаулык итә.

Югары әйтелгәннәрне исәпкә алып, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсенә республиканың төзәтү учреждениеләре хакимиятләренең игътибарын судларга җибәрелгән материалларның объективлыгына һәм тулы булуына, шулай ук азат итү турында юлламаны карау өчен әһәмиятле булган хәлләрне чагылдырмаган «шаблон» характеристикалар эшләү очракларына юл куймауга юнәлтүне максатка ярашлы дип саныйбыз.

Вәкилнең пенитенциар система органнары эшчәнлегенә контрольлек итүче субъектларның берсе булуын исәпкә алып, сак астына алынган тоткыннарның, иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәүче хөкем

ителгәннәрнең хокукларын һәм ирекләрен яклау белән бәйле мәсьәләләр аның игътибар үзәгендә калачак.

## Татарстан Республикасы гражданнарының бушлай юридик ярдәм алуга хокукларын тәэмин итү

Россия Федерациясе Конституциясенең 48 нче маддәсе барлык гражданнарның квалификацияле юридик ярдәм алуга хокукын билгели. Бертөсле юридик яклау белән тәэмин итү һәркемгә гарантияләнгән, шул ук вакытта дәүләт дәрәҗәсендә аерым игътибар социаль яклауга мохтаҗ гражданнарның шушы хокукын тормышка ашыруга юнәлтелә.

Бушлай юридик ярдәм турындагы законнар гражданнарга бушлай юридик ярдәм күрсәтүнең ике – дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган системасын күздә тота. Югары профессиональ дәрәҗәдә бушлай хокукый ярдәм күрсәтү – дәүләт өчен дә, юридик җәмәгатьчелек өчен дә мөһим бурыч.

Татарстан Республикасында бушлай юридик ярдәмнең дәүләтнеке булмаган системасында юридик клиникалар, дәүләтнеке булмаган бушлай юридик ярдәм үзәге һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар катнашучылар булып тора.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында югары белем бирүнең 8 мәгариф оешмаларында консультация, аналитика һәм хокук ярдәме күрсәтүне тормышка ашыручы юридик клиникалар төзелгән. Юридик клиникалар мәгълүматы буенча 2014 елда алар 1451 гражданга, 2015 елда 1702 гражданга бушлай ярдәм күрсәткән.

2013 елда Казан шәһәренең икътисад, идарә һәм хокук институты каршында Татарстан Республикасы бушлай юридик ярдәмнең дәүләтнеке булмаган үзәге оештырылган, аның белгечләре бушлай юридик ярдәм күрсәтә. Үзәк тормышка ашыра торган актуаль проектлар арасында пациентлар хокукларын, укучылар, чит ил гражданнары хокукларын яклауга юнәлтелгән проектлар бар.

Бушлай юридик ярдәмнең дәүләтнеке булмаган системасында катнашучылар гражданнарның бозылган хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау өчен тигез шартлар тудыруда мөһим роль уйныйлар, аларга коммерция оешмасына мөрәҗәгать итү мөмкинлеге булмаган һәм бушлай юридик ярдәмнең дәүләт системасында билгеләнгән критерийларына эләкмәүче гражданнар мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Законга ярашлы рәвештә бушлай юридик ярдәмгә хокукы булган гражданнар категорияләре исемлеге чикләнгән булуны исәпкә алып, бушлай юридик ярдәм күрсәтүдә шулай ук Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил институты да мөһим роль үти. Мәсәлән, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты, гражданнарга телдән һәм язмача консультация үткәрүдән тыш, кеше хокуклары һәм ирекләре , аларны яклауның формалары һәм ысуллары мәсьәләләре буенча хокукый агарту бурычын тормышка ашыру кысаларында, консультация һәм агарту характерында чаралар оештыра.( «Хокукый ярдәм көннәре», төрле максатчан аудиторияләр өчен Хокукый белемнәр мәктәбе, «түгәрәк өстәлләр», телефоннан «кайнар элемтәләр» ).

Татарстан Республикасы Прокуратурасы, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты, Россия Федерациясе Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе, кулланучылар хокукларын һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәтнең Татарстандагы идарәсе, Татарстан Республикасы мәҗбүри медицина иминиятенең территориаль фонды, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасындагы бүлеге, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы дәүләт торак инспекциясе, «Татарстан Республикасы Адвокат палатасы», «Татарстан Республикасы Нотариаль палатасы» коммерциячел булмаган оешмалары, «Россия пенсионерлары берлеге» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстандагы төбәк бүлеге, «Яңа гасыр» автоном хәйрия коммерциячел булмаган оешмасы, «Мигрантларга хокукый ярдәм күрсәтү

үзәге» иҗтимагый оешмасының төбәк бүлеге, социаль якланмаган катлауга хокукый ярдәм күрсәтү буенча «Юридик клиника» вәкилләре бу чараларның актив катнашучылары һәм социаль партнерлары булып тора.

Татарстан Республикасында гражданнарга бушлай юридик ярдәм күрсәтү буенча эшчәнлекне тормышка ашыручы социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар арасында Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән бушлай юридик ярдәм күрсәтү өлкәсендә төрле актуаль проектларны тормышка ашыручы «Россия юристлар берлеге» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлеге аеруча актив позиция алып тора.

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм алар карамагындагы учреждениеләр бушлай юридик ярдәмнең дәүләт системасы катнашучылары буларак, аларга кагылышлы мәсьәләләр буенча телдән һәм язмача хокукый консультацияләр рәвешендә бушлай юридик ярдәм күрсәтәләр. Республика башкарма хакимиятенең һәр органында бушлай юридик ярдәм күрсәтү буенча җаваплы затлар , гражданнарны кабул итү вакыты һәм көннәре билгеләнгән, рәсми сайтларда «Бушлай юридик ярдәм» дигән мәгълүмат бүлекләре оештырылган.

Татарстан Республикасында, Россия Федерациясенең күпчелек субъектларындагы кебек үк, бушлай юридик ярдәм күрсәтүгә адвокатлар җәмәгатьчелеге җәлеп ителгән. Ел саен, 2013 елдан башлап, 2011 елның 21 ноябрендә дөнья күргән 324 нче «Россия Федерациясендә бушлай юридик ярдәм турында» федераль законга һәм Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 24 маенда дөнья күргән УП-444 нче «Татарстан Республикасы территориясендә бушлай юридик ярдәмнең дәүләт системасында катнашучылар хезмәттәшлеге тәртибен раслау турында»гы указына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Адвокат палатасы һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы адвокатларның бушлай юридик ярдәм күрсәтүе турында килешүләр төзиләр.

Татарстан Республикасы Адвокат палатасы мәгълүматлары буенча, 2015 елда 203 граждан (2014 елда – 250) адвокатлардан юридик ярдәм алганнар. Аларга язмача һәм телдән консультацияләр (1497 консультацияләр), шикаятьләр, юлламалар, дәгъвалар, гаризалар һәм хокукый характердагы башка документлар төзү буенча – 831 ярдәм күрсәтелгән, 107 очракта судларда, дәүләт органнарында, оешмаларда вәкил буларак катнашканнар.

2014-2015 елларда беренче һәм икенче төркем инвалидлар, инвалид балалар, ятим балалар, әти-әни тәрбиясеннән мәхрүм балалар, Бөек Ватан сугышы ветераннары бушлай юридик ярдәм алучылар булган. Мөрәҗәгатьләрнең тематикасы – кулланучылар хокукларын яклау, гражданнарның торакка хокукын тормышка ашыру, күчемсез милек килешүләре, җир мөнәсәбәтләре, социаль яклау чаралары һәм алиментлар алу мәсьәләләре.

Бушлай юридик ярдәмнең дәүләт системасында катнашучы адвокатлар (2015 елның 24 декабренә 146 адвокат) Спасс муниципаль районыннан кала, Татарстан Республикасының барлык территориясендә эшлиләр. Күрсәтелгән районда яшәүче кешеләр якын районнардагы адвокатларның бушлай хезмәтләреннән файдалана ала.

2014-2015 елларда Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы Татарстан Республикасы Адвокат палатасы белән берлектә, бушлай юридик хезмәтнең дәүләт системасында катнашучылар булган адвокатларны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре күрсәтүнең күп функцияле үзәкләренә урнаштыру буенча эш башкарылды. Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы 27 муниципаль берәмлегендә гражданнар күп функцияле үзәкләрдә адвокатлар хезмәтләреннән файдалана ала.

Ләкин Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы мәгълүматлары буенча, дәүләт системасы катнашучылары булган 146 адвокатның бары 24 е генә 2014-2015 елларда бушлай юридик ярдәм күрсәткәннәр. 2015 елның 30 ноябрендә «Татарстан Республикасында

бушлай юридик ярдәмнең дәүләт системасы: алга таба үстерү юллары» дигән темага Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы оештырган «түгәрәк өстәл» утырышы кысаларында Татарстан Республикасы Адвокат палатасына бушлай юридик ярдәмнең дәүләт системасында катнашучылар булган адвокатларны өстәмә матди стимуллаштыру мөмкинлеге табарга кушылды.

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына гражданнардан бушлай юридик ярдәм күрсәткәндә адвокатлар гамәлләреннән зарланган шикаятьләр килә. Шикаятьләрне тикшергәч гражданнарның бушлай юридик ярдәм хокукыннан явызларча файдалануы ачыклана. «Түгәрәк өстәл» утырышында билгеләп үтүләренчә, мондый хәлләргә юл куймас өчен Санкт-Петербургта адвокатларның сан-сыйфат күрсәткечләрен күзәтеп бару тәҗрибәсе бар. Мәсәлән, бер үк кешенең икенче тапкыр адвокаттан бушлай юридик ярдәм алуы комиссиянең (коллегия) тиешле карары булган очракта гына мөмкин. Күрсәтелгән хәл гражданнар ягыннан явызларча файдалану мөмкинлеген юкка чыгара, адвокатлар да үз күрсәткечләрен арттырып күрсәтә алмый.

Бушлай юридик ярдәм системасын камилләштерү һәм бушлай ярдәмгә хокукны раслаучы документлар җыюны җиңеләйтү максатыннан, Вәкил 2016 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 12 ноябрендә дөнья күргән 863 нче карарында билгеләнгән, «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасы чикләрендә «Бушлай юридик ярдәм» системасын булдыруны мөһим дип саный.

Халыкка квалификацияле хокукый ярдәм һәм хокукый агартуга булышлык итү буенча эш гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен нәтиҗәле яклауда, халыкның юридик грамоталыгы дәрәҗәсен күтәрүдә, шәхестә хокукый активлык формалаштыруда, гражданлык җәмгыяте һәм хокукый дәүләт булдыруда иң мөһим факторларның берсе булып тора.

Шунысын да ассызыклау мөһим, Татарстан Республикасында бушлай юридик ярдәм алуга гражданнарның хокукларын тормышка ашыру өчен кирәкле норматив хокукый база бар. 2013 елның 1 гыйнварыннан 2011 елның 21 декабрендә дөнья күргән 324 нче «Россия Федерациясендә бушлай юридик ярдәм турында» федераль законга нигезләнеп кабул ителгән, 2012 елның 2 ноябрендә дөнья күргән 73 нче "Татарстан Республикасында гражданнарга бушлай юридик ярдәм күрсәтү турында» республика законы эшли. Бу законны үтәү өчен норматив актлар кабул ителде.

Хәзерге вакытта республикада бушлай юридик ярдәм күрсәтү буенча эшне үстерү һәм камилләштерү, күрсәтелә торган хокукый ярдәм сыйфатын тәэмин итү һәм бу конституцион хокукларын нәтиҗәле тормышка ашыру өчен гражданнарга шартлар булдыруга булышлык итү бурычы куела.

## Йомгак

Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклау буенча хәлгә бәя биргәндә макродәрәҗә факторларын исәпкә алмыйча булмый. Узган 2015 ел халык тормышы дәрәҗәсенә тәэсир итүче икътисадый хәлнең үзгәрүе белән истә калды.

Халыкның чын табышы кимүгә китергән икътисадый авырлыклар чагылышында дәүләт органнарыннан гражданнарның хезмәткә хокукларын саклау һәм тәэмин итү буенча нәтиҗәле чаралар кабул итү көтелә. Эш хакы түләмәү, законда каралмаган нигезләрдә эш хакын тоткарлау, эш бирүчеләрнең эш хакын бирүдән качуы, хезмәт мөнәсәбәтләрен теркәмәве очракларында хезмәткәрләрнең хезмәткә хокукларын яклау гарантияләрен көчәйтү буенча чаралар таләп ителә.

Республикада производствода имгәнүләрне киметү буенча максатчан эш алып барыла. Җитештерүдә бәхетсезлек очракларына юл куйган эш бирүчеләргә җәза бирү буенча системалы эштән һәм производство имгәнүләре һәм һөнәри авырулар профилактикасы буенча чаралардан тыш,

сәламәт һәм имин хезмәт шартларын популярлаштыруга, моңа хезмәткәрләрнең үзләренең күбрәк кызыксынуына мөһим әһәмият бирелергә тиеш.

Ел дәвамында республикада торак төзү буенча бурыч планлы рәвештә хәл ителде, бу күрсәткеч буенча Татарстан чираттагы тапкыр Россия Федерациясе субъектлары арасында иң яхшыларның берсе булды. Төзелеш һәм торакны сафка бастыру темпларының югары булуына карамастан, республиканың аз тәэмин ителгән гражданнарының торак шартларын яхшырту проблемасы үз актуальлеген югалтмый. Социаль найм килешүе буенча торак бирүне оештыру эше нәтиҗәлерәк булырга тиеш. Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, шулай ук Бөек Ватан сугышы ветераннарының торакка хокукларын тормышка ашыруга зур игътибар бирелергә тиеш.

Үзбелдеклеләнеп төзелгән, дип танылган торак биналарыннан гражданнарны чыгару очраклары күбәюгә юл куймау максатыннан, намуссыз төзүчеләрнең эшенә үз вакытында чик кую чаралары булдыру кирәк. Төзүгә тиешле рөхсәттән башка төзелгән торак йортлары булу фактларын исәпкә алып, бу юнәлештә нәтиҗәле эш алып барылырга тиеш.

Сәламәтлек саклауны үстерү башлангыч медицина ярдәменең нәтиҗәле системасыннан башка мөмкин түгел. Узган ел йомгаклары буенча, контрольлек итүче органнарга гражданнардан медицина ярдәме сыйфатыннан зарланып килгән шикаятьләр саны кимеми. Гражданнар өчен дәүләт гарантияләре белән ярашлы рәвештә медицина ярдәме күләме турында медицина учреждениеләре сайтларында мәгълүмат урнаштыру буенча эш җитәрлек түгел.

Узган ел йомгаклары республиканың кайбер муниципаль берәмлекләрендә туберкулез белән авыручылар арту тенденциясе барлыкка килүне булдырмау өчен өстәмә чаралар кирәклеген күрсәтә. Республиканың берничә муниципаль берәмлекләрендә онкологик авырулардан үлүчеләр саны арту һәм беренче тапкыр беленгән яман шешләрнең соңгы чиктә

ачыклануы сизелерлек арту онкологик авыруларны иртә ачыклау мәсьәләсен актуальләштерә.

2015 елны республикада Парклар һәм скверлар елы дип, ә 2016 елны Су саклау зоналары елы дип игълан итү Татарстанда халыкның экология иминлеге белән бәйле мәсьәләләрне аңлауның мөһимлеген дәлилли. Гражданнарның су объектларына ирекле рәвештә керүен чикләү, судан законсыз рәвештә файдалану фактларына юл куймау белән беррәттән, сәнагать предприятиеләренең су объектларын пычратуы очракларына үзвакытында игътибар итәргә кирәк.

Республикада инвалидларның икътисадый халыкара стандартларын, инвалидларның социаль һәм башка хокукларын саклауга юнәлтелгән шартларын формалаштыруга зур әһәмият бирелә. Инвалидларның физик тирәлеккә, транспортка, мәгълүматка һәм элемтәгә, шулай ук халыкка ачык булган яки күрсәтелгән башка объектларга һәм хезмәтләргә керүен тәэмин итү буенча күрелә торган чараларга карамастан, инвалидларның уңайлы тирәлеккә хокукларын тормышка ашыру белән бәйле берничә кискен проблема кала.

Тәкъдим ителә торган эш шартлары һәм махсус эш урынын җиһазлау буенча тәкъдимнәр турында эш бирүчеләрдә җитәрлек мәгълүмат булмау аркасында инвалидларны һөнәри тернәкләндерүдә аерым кыенлыклар бар. Социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре күзәтчелегенә урнаштырылган акылга зәгыйфь гражданнарның хокукларын саклауга игътибарлырак караш таләп ителә.

Татарстан элеккечә үк мигрантлар өчен үзенә җәлеп итүче төбәк булып кала. Республикада яшәүчеләрнең мигрантлар белән үзара мөнәсәбәтләре тотрыклылыгы шартларының берсе булып, чит ил гражданнарының Россия Федерациясе территориясенә законлы килүенә рөхсәт бирүче статус алуы тора. Вакытлыча яшәп торырга рөхсәт алырга теләүче чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның саны ел саен билгеләнгән квотадан артып китә, аны төгәл бүлү механизмы кирәк.

Чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларның Россия Федерациясе законнарын бозуы Россия Федерациясе чикләреннән оператив чыгарып җибәрү мөмкинлеге булмау аркасында мигрантларны махсус учреждениеләрдә озак айлар тотуга китерергә мөмкин. Кызганычка каршы, республикада гражданлыгы булмаган затлар буенча шундый хәл бар.

2015 ел йомгаклары буенча, мәҗбүри тоту урыннарында кеше хокукларын саклау буенча вәзгыять уңай. Шуның белән бергә, Россия Федерациясендәге башка субъектларның тәҗрибәсен исәпкә алып, irектән мәхрүм итү урыннарында тотылган наркобәйлелектән һәм алкоголь бәйлелектән җәфа чигүче затларга карата социаль-психологик ярдәм күрсәтүне активлаштырырга кирәк. Төзәтү учреждениеләре хакимиятләренең хөкем ителүчеләрне вакытыннан алда шартлы рәвештә азат итү турында суд органнарына җибәргән характеристикаларын әзерләү эшендә кимчелекләр бар.

Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм вазифадагы затларның кеше һәм граждан ирекләрен һәм хокукларын саклау принципын хөрмәтләүнең аерылгысыз билгесе – халыкны хокукый агарту.

Югарыда әйтелгәннәрне исәпкә алып, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклауны тәэмин итү һәм көчәйтү максатларында Вәкил дәүләт органнарына, җирле үзидарәләр органнарына һәм вазифадагы затларга түбәндәге чараларны кабул итәргә тәкъдим итә.

1. Хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә кеше хокукларын тормышка ашыру максатларында:

1.1. Хезмәт законнарын саклауга күзәтчелекне тормышка ашыручы дәүләт органнарына:

эш хакы буенча бурыч күләмен арттыруга юл куйган эш бирүчеләргә карата хокукый чаралар кабул итү эшчәнлеген көчәйтергә;

эш хакыннан хезмәт законнарында каралмаган сәбәпләр буенча акча тотып калу очракларын булдырмау буенча эшне көчәйтергә;

хезмәт хокукларын бозу турында шикаятьләр килгән, чынбарлыктагы адреслары юридик затларның бердәм дәүләт реестрындагы белешмәләргә туры килмәгән эш бирүчеләрнең урнашу урынын ачыклау буенча эшчәнлекне көчәйтергә.

1.2. Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясенә, республика тармак профсоюз органнарына, Татарстан Республикасы эш бирүчеләр координацион советына җитештерү эшчәнлеген тормышка ашыручы оешмаларның күмәк килешүләренә кертүгә йөз тоткан чараларны тормышка ашырырга, җитештерү имгәнүләрен киметүгә, авыр һәм зарарлы хезмәт шартлары булган эш урыннарын кыскартуга, хезмәт шартлары буенча махсус бәяләү үткәрүгә һәм аны тормышка ашыру өчен кирәкле акча бүлүгә юнәлтелгән чараларны тормышка ашырырга.

1.3. Халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, Татарстан Репсубликасына чит ил гражданнарын җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясенә хезмәт хокукларын бозу турында шикаятьләр килгән, чынбарлыктагы адреслары юридик затларның бердәм дәүләт реестрындагы белешмәләргә туры килмәгән эш бирүчеләргә карата күзәтчелек чаралары үткәргәндә ведомствоара хезмәттәшлек турындагы мәсьәләне карарга.

1.4. Җирле үзидарәләр органнарына «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына килгән «Хезмәт мөнәсәбәтләрен теркәмәү» төрендәге белдерүләрне карау кысаларында, һәр очракта эш бирүче эш үтәү яки хезмәт күрсәтү өчен белгечләр җыйганда башкарган барлык хәлләрне исәпкә алып, граждан-хокукый килешүләр төзүнең законга ярашлыгы фактын тикшерергә.

2. Гражданнарның торакка хокукларын тормышка ашыру максатларында:

2.1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау

министрлыгы белән берлектә, торак милекчеләре булган яки торак алып торган, 18 яше тулганчы мәгариф, медицина һәм социаль хезмәт күрсәтүче оешмаларда булган ятим балаларның тораклары сакланышы буенча мониторинг системасын эшләргә;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре һәм шәһәр округларының опека һәм попечительлек органнары белән берлектә, 2013 елның 12 гыйнварында дөнья күргән 8-ЗРТ номерлы «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итү» турындагы законның 4 өлеш 1 маддәсендә һәм «Татарстан Республикасында халыкны адреслы социаль яклау турында»гы законның 8 маддәсенә үзгәрешләрдә күрсәтелгән сәбәпләр булган очракта, ятим балалар һәм ата-анасы тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның опекуннарыннан торакны мәҗбүри алыштыру турында дәгъва гаризалары бирү буенча эшне оештырырга;

җирле үзидарә органнары белән берлектә ятим балаларның торак-коммуналь хезмәтләргә булган бурычын киметү буенча системалы эшне тормышка ашырырга.

2.2.Җирле үзидарәләр органнарына:

торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган гражданнарга муниципаль торак фондының буш торак биналарын социаль найм килешүе буенча бирү һәм төзекләндерү буенча чаралар күрергә;

торак биналарын яшәү өчен яраксыз һәм сүтәргә тиешле дип таныган, аларда федераль бюджет исәбеннән торак белән тәэмин ителү хокукына ия булган Бөек Ватан сугышы ветераннары яшәгән очракларда андый гражданнарны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар сыйфатында исәпкә бастыру буенча кичектергесез чаралар күрергә;

күпквартирлы йортларны яки күпквартирлы йортта биналарны үзбелдеклеләнеп төзелгән корылма дип тану турында судка дәгъва гаризасы биргән очракларда, һәр очракта дәгъваны тәэмин итү буенча чара сыйфатында килешүне тыю турында юллама белән мөрәҗәгать итәргә;

дәгъва гаризалары бирү турында карарлар кабул итүгә дифференцияле карау очракларын, шул исәптән үзбелдеклеләнеп төзелгән объектларны беренче караган көннән алып дәгъва гаризалары бирү буенча чаралар кабул итүне көйләгән карар бастыру очракларын бетерергә.

3. Гражданнарның сәламәтлек саклауга һәм медицина ярдәменә хокукларын тормышка ашыру максатларында:

3.1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау учреждениеләренә аларның сайтларында гарантияле бушлай медицина ярдәме күрсәтү күләме, табиб-белгечләрнең консультацияләр бирү, диагностик инструменталь һәм лаборатор тикшеренүләр үтү буенча нормада каралган вакыт турында тулы мәгълүмат бирүне оештырырга;

медицина ярдәме күрсәтү сыйфатыннан зарланган нигезле шикаятьләр санын киметү буенча эшне көчәйтергә;

туберкулезны ачыклау максатыннан профилактик медицина тикшеренүләре үтмәгән гражданнар санын киметүгә юнәлтелгән чаралар эшләргә;

онкологик авыруларны иртә ачыклау буенча өстәмә чаралар күрергә.

4. Гражданнарның уңайлы әйләнә-тирәлеккә хокукларын тормышка ашыру максатларында Дәүләт экологик күзәтчелеген тормышка ашыручы органнарга хуҗалык итүче субъектларның ташландык суларны чистарту буенча билгеләнгән таләпләрне үтәвенә контрольне көчәйтергә.

5. Инвалидларның хокукларын тормышка ашыру максатларында:

5.1.Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына авыруы аркасында утыргыч-арбадан файдаланучы инвалидларның гаризалары булган очракта, үз-үзенә хезмәт күрсәтү һәм хәрәкәт итү мөмкинлекләре 2 нче һәм 3 нче дәрәҗәдә чикле булган инвалидның шәхси милкендәге торагын “Социаль ипотека» программасы буенча төзелгән, күпквартирлы йортларның беренче катында урнашкан торакка күчерү буенча норматив акт кабул итү мәсьәләсен карарга.

5.2. Медико-социаль экспертиза федераль дәүләт учреждениеләренә инвалидларның тернәкләндерү, абилитация индивидуаль программаларында хезмәт эшчәнлеге алып барырга мөмкин булган инвалидларга шартларны тулысынча язмау очракларына юл куймаска.

5.3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең һәм шәһәр округларының опека һәм попечительлек органнарына акылга зәгыйфь дип танылган гражданнарны медицина оешмаларына яки социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмаларга урнаштырганда, аларның опекуннарын вазифаларыннан азат итү очракларын бетерергә.

5.4. Казан шәһәре башкарма комитетына хәрәкәтләнүе чикле булган өченче төркем инвалидларны Казан шәһәренең җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында түләүле муниципаль парковкаларга (туктау урыннарына) түләүдән азат итү мәсьәләсен карарга.

6. Чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның хокукларын тормышка ашыру максатларында:

6.1.Россия Федераль миграция хезмәтенең Татарстандагы идарәсенә, булган суд практикасын истә тотып, чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга Россия Федерациясендә вакытлыча яшәп торуга рөхсәткә мөстәкыйль квота бүлү очракларын бетерергә.

6.2. Суд приставлары Федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсенә гражданлыгы булмаган затларга карата, Россия Федерациясе чикләреннән тиз арада чыгарып җибәрү турында башкарма документларны үтәп булмауны дәлилләгән фактлар ачыкланган очракларда административ эшләр буенча үтәү производствосын туктату турында суд приставлары-башкаручыларының гаризаларын суд органнарына бирү эшен оештыру мәсьәләсен карарга.

7. Мәҗбүри тоту урыннарында тотылучы затларның хокукларын тормышка ашыру максатларында:

7.1.Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсенә:

иректән мәхрүм итү урыннарында булган наркобәйлелек һәм алкогольгә бәйлелеккә дучар тоткыннарны тернәкләндерү эше буенча Россия Федерациясенең башка субъектларында булган тәҗрибәне куллану мәсьәләсен карарга;

хөкем ителүчеләрнең вакытыннан алда шартлы рәвештә азат итү турында юлламаларын карау өчен төзәтү учреждениеләре хакимиятләренә судларга объектив һәм тулы материаллар җибәрү мәсьәләсен карарга.

8. Бушлай юридик хезмәт күрсәтү эшен камилләштерү максатларында:

8.1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына:

Татарстан Республикасында бушлай юридик ярдәм күрсәтү системасын комплекслы үсешен тәэмин итү буенча эшне алга таба да камилләштерү буенча чаралар күрергә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 12 ноябрендә 863 нче «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасы турында» карары белән билгеләнгән «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасы чикләрендә «Бушлай юридик ярдәм” системасын булдыру мәсьәләсен карарга;

Хәрби хәрәкәтләр ветераннарын, өченче төркем инвалидларны Татарстан Республикасында бушлай юридик ярдәмнең дәүләт системасы кысаларында бушлай юридик ярдәм алуга хокуклы гражданнар категорияләре исемлегенә кертү мөмкинлеген карарга;

Бушлай юридик хезмәтләр күрсәтүче үзәкләр турында мәгълүмат урнаштыру һәм порталда бушлай онлайн һәм оффлайн консультацияләр үткәрү мөмкинлеген тәэмин итү белән Татарстан Республикасы бушлай юридик ярдәм Бердәм республика порталын булдыру мөмкинлеген карарга;

Хокукның актуаль һәм таләп ителгән өлкәләре буенча агарту программалары эшләү белән халыкның хокукый грамоталыгын күтәрү өчен якшәмбе курслары оештыру мөмкинлеген карарга.

8.2. Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча «Татмедиа» республика агентлыгына халыкның бушлай юридик ярдәм алу мөмкинлекләре турында, Татарстан Республикасының хокукый агарту буенча үрнәк тәҗрибәсе турында мәгълүмат таратырга.

**Татарстан Республикасында**
**Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил С.Х. Сабурская**

2016 ел, гыйнвар

**ДОКЛАД УПОЛНОМОЧЕННОГО ПО ПРАВАМ ЧЕЛОВЕКА В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН**

**О СОБЛЮДЕНИИ ПРАВ И СВОБОД ЧЕЛОВЕКА И ГРАЖДАНИНА В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН В 2015 ГОДУ**

Аппарат Уполномоченного по правам человека в Республике Татарстан
Адрес: 420015, г. Казань, ул. К. Маркса, 61
Тел./факс: (843) 236-41-80
E-mail: tat.ombudsman@tatar.ru
www.upch.tatarstan.ru

Отпечатано в типографии «ЗурКазан».
Тираж 250 экз.
420095, г. Казань, ул. Серова, 4а
Тел.: (843) 253-58-33

***

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА КЕШЕ ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛ ДОКЛАДЫ**

**2015 ЕЛДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА КЕШЕ ҺӘМ ГРАЖДАННЫҢ ХОКУКЛАРЫН ҺӘМ ИРЕКЛӘРЕН САКЛАУ ТУРЫНДА**

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты
Адрес: 420015, Казан ш., К. Маркс ур., 61
Тел./факс: (843) 236-41-80
E-mail: tat.ombudsman@tatar.ru
www.upch.tatarstan.ru

«ЗурКазан» типографиясендә нәшер ителде
Тираж 250 данә.
420095, Казан ш., Серова ур., 4а
Тел.: (843) 253-58-33